| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>РЫБНО-СЛОБОДСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>РЫБНО-СЛОБОДСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛЫК БИСТӘСЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАЛЫК БИСТӘСЕ<br>ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2025 елның 1 апреленнән Балык Бистәсе штп. № 4осн

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 16 октябрендәге 15осн номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча Эш тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, “Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 2023 елның 9 декабрендәге 124-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 16 октябрендәге 15осн номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча Эш тәртибенә (23.05.2018 ел №12осн; 01.04.2019 ел №4осн боерыклар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 1.2 пунктының 3 абзацында «электрон почта адресы» сүзләреннән соң «яисә Бердәм порталдагы шәхси кабинет адресы» сүзләрен өстәргә;

1.2) 2.12 пунктының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күмәк мөрәҗәгатькә җавап юллау турындагы гозер мөрәҗәгать иткән (имза куйган) берничә зат тарафыннан белдерелгән очракта җавап күчермәсе аларның һәркайсына үзләре күрсәткән почта адреслары яки шәхси кабинетлар адреслары буенча Бердәм порталда җибәрелә.».

2. Әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе штп., Ленин урамы, 48А йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм

http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3.Боерыкның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Җитәкче М.В. Мәгыйзов